ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОБУРУНДУКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Улица Вокзальная, дом 31,
П.ж.-д.ст.Бурундуки, Дрожжановский район
422490

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА БОРЫНДЫК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Вокзал урамы, 31 нче йорт,
Борындык тимер юл ст. поселогы,
Чүпрәле районы
422490

Тел.: (84375) 3-17-45, 3-17-03, факс: (84375) 3-17-45, e-mail: Nbur.Drz@tatar.ru,
www. Nbur -drogganoe.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

13.12.2022 № 17

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Яңа Борындык авыл җирлеге территориясендә чүп-чарны, үләнне, яфракларны һәм башка калдыкларны яндыру урыннарына һәм ысулларына үзгәреш кертү турында

«Россия Федерациясендә янгынга каршы режим кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 24 октябрендәге 1885 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Яңа Борындык авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

«Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Яңа Борындык авыл җирлеге территориясендә чүп-чар, үләннәр, яфраклар һәм башка калдыкларны яндыру урыннарын һәм ысулларын билгеләү турында» 2018 елның 15 мартындагы 6 номерлы Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты карарына, 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Борындык авыл җирлегенең торак пунктлары территорияләрендә урнашкан торак пунктларның гомуми кулланылыштагы җирләрендә, шулай ук хосусый йорт биләмәләрендә азык әзерләү өчен махсус бүлеп бирелгән һәм җиһазландырылган урыннардан читтә ачык ут куллану, шулай ук чүп-чар, үлән, яфрак һәм башка калдыклар, материаллар яисә эшләнмәләр яндыру тыела.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыгарга тиеш.

Яңа Борындык авыл
җирлеге башлыгы



В.Г. Ранцев